МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.02.2025 Казан ш. № 51

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 13 апрелендәге 138 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 13 апрелендәге 138 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 11 августындагы 304 номерлы, 2023 елның 7 мартындагы 50 номерлы, 2024 елның 22 мартындагы 80 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2025 елның 5 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары Г.И.Исмәгыйловага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр М.Р.Шаһиәхмәтов

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 28.02.2025 ел, №51 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 13 апрелендәге 138 номерлы боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лицензияләр реестрыннан өземтә яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә, ул лицензияләр реестрында лицензияләр турында белешмәләр булмаган очракта яки конкрет лицензиатны билгеләү мөмкин булмаган очракта бирелә.»;

2.4 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гариза кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.6.1 пунктта:

1 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) лицензия бирү турында электрон документ рәвешендә бирелә торган гариза;»;

2 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында электрон документ рәвешендә бирелә торган гариза;»;

3 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында электрон документ рәвешендә бирелә торган гариза.»;

5 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«лицензиатның лицензияне гамәлдән чыгару турында электрон документ рәвешендә бирелә торган гаризасы.»;

6 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында электрон документ рәвешендә бирелә торган гариза.»;

3 бүлектә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча да;

2) лицензия бирү:

а) гаризаны автомат рәвештә ТОР КНД дәүләт мәгълүмат системасында теркәү;

б) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү;

в) лицензия таләпләренең үтәлешен күчмә бәяләүне үткәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен лицензиягә дәгъва кылучыга җибәрү;

3) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәртелгән очракларда):

а) гаризаны автомат рәвештә ТОР КНД дәүләт мәгълүмат системасында теркәү;

б) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү;

в) лицензия таләпләренең үтәлешен күчмә бәяләүне үткәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен лицензиатка җибәрү;

4) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракта):

а) гаризаны автомат рәвештә ТОР КНД дәүләт мәгълүмат системасында теркәү;

б) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен лицензиатка җибәрү;

5) лицензиянең гамәлдә булуын туктату:

а) гаризаны автомат рәвештә ТОР КНД дәүләт мәгълүмат системасында теркәү;

б) Бердәм порталдан алынган гаризаны кабул итү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен лицензиатка җибәрү;

6) лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү:

а) гаризаны автомат рәвештә ТОР КНД дәүләт мәгълүмат системасында теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен автомат режимда әзерләү;

в) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен автомат режимда лицензиатка җибәрү;

7) техник хаталарны төзәтү.»;

3.3 пунктта:

3.3.3 пунктчасының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензиягә дәгъва кылучыга  ачыкланган бозуларны утыз көн эчендә бетерү һәм (яки) электрон документ формасында булмаган документларны лицензияләү органының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган

документ формасында тапшыру кирәклеге турында шәхси кабинетка хәбәр җибәрә. Лицензия алырга теләүче зат тарафыннан, белдерү алынган вакыттан башлап, лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза яки аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензия бирү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензия алырга теләүче затка әлеге срок узган көннән алып өч эш көне узганчы кире кайтарылырга тиеш.

3.3.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.5. Бүлек белгече (белгечләре) лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен гариза бирелгән урында лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирә.

Лицензия таләпләрен үтәүне күчмә бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләү акты рәсмиләштерелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Процедура Регламентның 3.3.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне узгач гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү акты.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.5$^{1}$ пунктчасын өстәргә:

«3.3.5$^{1}$. Бүлек белгече лицензия алырга теләүчегә, мондый актны лицензия алырга теләүчегә теләсә нинди ысул белән җибәреп, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә, Бердәм порталда лицензия алырга теләүченең шәхси кабинетыннан файдаланып, лицензия алырга теләүченең электрон почтасы адресына бәяләү актын рәсмиләштерү факты турында хәбәр итә. Лицензия алырга теләүчегә мондый актны лицензия алырга теләүчегә турыдан-туры күчмә бәя бирү урынында тапшыру юлы белән бәяләү актын рәсмиләштерү факты турында хәбәр ителергә мөмкин. Лицензия алырга теләүчегә бәяләү актын Бердәм портал аша рәсмиләштерү факты турында хәбәр ителгән очракта, әгәр бәяләү акты көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү процедурасын узган лицензиягә дәгъва кылучыга Бердәм портал аша мондый актны җиткерү фактып раслап җибәрелгән булса, лицензия алырга теләүчегә бәяләү актын тиешенчә рәсмиләштерү факты турында хәбәр ителгән дип санала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар бәяләү акты рәсмиләштерелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү актын рәсмиләштерү факты турында хәбәр итү.»;

3.4 пунктта:

3.4.3 пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензиатка ачыкланган бозуларны утыз көн эчендә бетерү һәм (яки) электрон документ формасында булмаган документларны лицензияләү органының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документ формасында тапшыру кирәклеге турында шәхси кабинетка хәбәр җибәрә. Лицензиат тарафыннан, белдерүне алган вакыттан башлап, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла

торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензиатка күрсәтелгән срок беткән көннән алып өч эш көне узганчы кире кайтарылырга тиеш.

3.4.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Бүлек белгече (белгечләре) лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен гариза бирелгән урында лицензия таләпләрен үтәүгә күчмә бәя бирә.

Лицензия таләпләрен үтәүне күчмә бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләү акты рәсмиләштерелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Процедура Регламентның 3.4.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне узгач гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү акты.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4.5[1] пунктчасын өстәргә:

«3.4.5[1]. Бүлек белгече лицензиатка бәяләү актын рәсмиләштерү факты турында мондый актны лицензиатка теләсә нинди ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә, Бердәм порталдагы лицензиатның шәхси кабинетыннан файдаланып, лицензиатның электрон почта адресына җибәрү юлы белән хәбәр итә. Лицензиатка бәяләү актын рәсмиләштерү факты турында лицензиатка күчмә бәяләү башкарылган урында ук тапшыру юлы белән хәбәр ителергә мөмкин. Лицензиатка бәяләү актын Бердәм портал аша рәсмиләштерү факты турында хәбәр ителгән очракта, әгәр бәяләү акты көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү процедурасын узган лицензиатка Бердәм портал аша мондый актны җиткерү фактып раслап җибәрелгән булса, лицензиатка бәяләү актын тиешенчә рәсмиләштерү факты турында хәбәр ителгән дип санала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар бәяләү акты рәсмиләштерелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү актын рәсмиләштерү факты турында хәбәр итү.»;

3.5.3 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензиатка белдерүне алган вакыттан башлап ачыкланган бозуларны утыз көн эчендә бетерү һәм (яки) электрон документ формасында булмаган документларны лицензияләү органының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документ формасында тапшыру кирәклеге турында шәхси кабинетка хәбәр җибәрә. Лицензиат тарафыннан, белдерүне алган вакыттан башлап, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензиатка күрсәтелгән срок беткән көннән алып өч эш көне узганчы кире кайтарылырга тиеш.

3.7.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.2. Конкрет лицензия турында белешмәләр мөрәҗәгать итүчегә автомат режимда бирелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура Регламентның 3.7.1 пунктчасында каралган процедураны үтәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрыннан конкрет лицензия турында өземтә яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә.

Конкрет лицензия турындагы белешмәләр көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә яисә соратыла торган белешмәләрнең булмавы турындагы белешмә рәвешендә җибәрелә.»

Регламентка 1-4 номерлы кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

(белешмәлек) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Кара металл, төсле металл ватыклары әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны күрсәтүне контрольдә тотучы органнар һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 524-91-11 | mert.pr1@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 524-91-02 | Gulnaz.Ismagilova@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлеге җитәкчесе | 524-91-48 | Nadezhda.Gornovskaya @tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | 524-91-49 | L.Safin@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече | 524-90-22 | Hasanova.Elmira@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты | 524-91-49 | Olga.Bobkova@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 524-91-68 | Ramziya.Zimina@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәнәгать бүлеге җитәкчесе | 264-76-74 | German.Fashiev@tatar.ru». |